РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 17 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 36/3**

Чистай муниципаль районы
Советының «Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлегендә бюджет
процессы турында нигезләмәне раслау
хакында» 2020 елның 18 февралендәге
54/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2020 елның 18 февралендәге карары (Чистай муниципаль районы Советының 28.10.2020 ел, № 2/2, 20.10.2021 ел, № 10/2, 27.05.2022 ел, № 15/2, 10.03.2023 ел, №21/1, 13.12.2023 ел, № 27/3 карарлары) белән расланган Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяда:

1.1.1. 5 пунктның 15 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт (муниципаль) контрактлар дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар планына ярашлы рәвештә төзелә һәм, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә.»;

1.1.2. 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга субсидияләр - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә түләүсез һәм кире кайтарылмас нигездә товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә) бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплау һәм (яисә) чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында күрсәтелә (тәмәке һәм алкоголь продукциясеннән тыш, экспортка җибәрү өчен билгеләнгән алкоголь продукциясеннән, виноградтан, күрсәтелгән виноград: шәраблар, күбекле шәраблар (шампан шәрабы), географик яктан якланган, килеп чыгу урыны исеме якланган ликер шәраблары (махсус шәраблар), шәраб материаллары, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында башкасы каралмаган булса), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү.».

1.2. 29 статьяның 3 пунктында:

1.2.2. Унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү гамәлләрен финанс белән тәэмин итүгә яңадан кертелгән очракта.»;

1.2.3. Соңгы абзацта «норматив йөкләмәләрдән» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 7 пунктының егерме бишенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru)«Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов